ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.03.2022 г. Казань № 18-10/тп-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2022 елга «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә газ куллану җайланмасын технологик тоташтырган өчен түләү күләмен билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкалары күләмнәрен билгеләү турында» 16.12.2021 № 632-239/тп-2021 карарына 2 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газ бәяләрен, аны транспортлаштыру хезмәтләренә тарифларны һәм газдан файдалану җайланмасын Россия Федерациясе территориясендә газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау өчен түләүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карарына, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Газдан файдалану җайланмасын газ бүлү челтәрләренә технологик ялгау өчен түләү күләмен һәм (яки) аның зурлыгын билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкаларын раслау турында» 2018 елның 16 августындагы 1151/18 номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2022 елның 30 мартындагы 6-ПР номерлы Идарә утырышы беркетмәсенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2022 елга «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең газ бүлү челтәрләренә газ куллану җайланмасын технологик тоташтырган өчен түләү күләмен билгели торган стандартлаштырылган тариф ставкалары күләмнәрен

билгеләү турында» 16.12.2021 № 632-239/тп-2021 карарына 2 нче кушымтага үзгәреш кертеп, түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктын өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «1.1. | Газ куллану челтәрен проектлауга СТС (җир төзелеше эшләре, инженерлык эзләнүләре, экспертиза үткәрү чыгымнарыннан тыш, эш документларын эшләүгә) | $C^{пр}$ | сум | 25 303,00». |

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев